ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«02» июнь 2026 ел № 555

**Арча муниципаль районы башкарма комитетының “Юридик затларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетыннан кулланучылар кооперациясе оешмаларының беренче кирәк-ярак товарларын Арча муниципаль районы үзәгеннән – Арча шәһәреннән 11 километр ераклыкта урнашкан авыл торак пунктларына илтеп җиткерүгә бәйле чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе турында” 2022 елының 22 июлендәге 692 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2023 елның 6 июнендәге 535 номерлы, 2023 елның 7 декабрендәге 1115 номерлы, 2024 елның 6 декабрендәге 961 номерлы, 2025 елның 3 июлендәге 628 номерлы, 2025 елның 20 ноябрендәге 1124 номерлы үзгәрешләр белән )**

Кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча муниципаль районы башкарма комитетының “Юридик затларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетыннан кулланучылар кооперациясе оешмаларының беренче кирәк - ярак товарларын Арча муниципаль районы үзәгеннән – Арча шәһәреннән 11 километр ераклыкта урнашкан авыл торак пунктларына илтеп җиткерүгә бәйле чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе турында” 2022 елының 22 июлендәге 692 номерлы карарына (2023 елның 6 июнендәге 535 номерлы, 2023 елның 7 декабрендәге 1115 номерлы, 2024 елның 6 декабрендәге 961 номерлы, 2025 елның 3 июлендәге 628 номерлы, 2025 елның 20 ноябрендәге 1124 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы үзәгеннән – Арча шәһәренән 11 километр ераклыкта урнашкан авыл торак пунктларына беренчел кирәк-ярак товарларын илтеп җиткерүгә бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр алу хокукына дәгъва кылучы юридик затларны сайлап алуны гамәлгә ашыручы комиссия составын яңа редакциядә, кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары Р.Р. Филипповага йөкләргә.

Җитәкче Л.И.Әбдуллин

*Арча муниципаль районы*
*Башкарма комитетының*
*2026 елның 02 июль*
*555 номерлы карарына*
*1 нче кушымта*

**Кулланучылар кооперациясе оешмаларының Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының район үзәгеннән – Арча шәһәреннән 11 километр ераклыкта урнашкан авыл торак пунктларына беренче кирәк-ярак товарларын илтүгә бәйле чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр алу хокукына дәгъва кылучы юридик затларны сайлап алуны гамәлгә ашыручы комиссия**

**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Филиппова Регина Рамил кызы | - Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары, комиссия рәисе; |
| Зиннатуллин Рөстәм Рушан улы | - Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Гыйззәтуллина Алинә Фәрхәт кызы | - Арча муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм финанс бүлеге башлыгы, комиссия секретаре; |
| *Комиссия әгъзалары:* | |
| Ганеева Эльмира Нияз кызы | - “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы” МКУ җитәкчесе (килешү буенча); |
| Сәгыйтова Ләйсән Гарафетдин кызы | - Арча район Советы Аппаратының юридик мәсьәләләр бүлеге җитәкчесе (килешү буенча); |
| Рахимҗанова Ильфира Бильсур кызы | - Арча муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге баш белгече. |